СОВЕТ
ЯНГА - САЛСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Центральная, д.18, с. Янга-Сала,
Арский муниципальный район, 422011

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЯҢАСАЛА
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Үзәк урам, 18 йорт, Яңасала авылы,
Арча муниципаль районы, 422011

Тел. (84366) 57-2-10, факс (84366) 57-2-10. E-mail: Yns.Ars@tatar.ru www.arsk.tatarstan.ru

**Арча муниципаль районы Яңасала авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

**« 10 » сентябрь 2024 ел** **№ 102**

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Яңасала авыл җирлеге Советының 2023 елның 29 нчы ноябрендәге 86 нчы номерлы «Физик затлар мөлкәтенә салым турынды» карарына үзгәрешләр кертү хакында.**

Россия Федерациясе Салым кодексының 32 бүлеге, «Татарстан Республикасы территориясендә физик затлар мөлкәтенә салым буенча салым базасын билгеләү тәртибенең бердәм датасын билгеләү турында» 2014 елның 30 октябрендәге 82-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, салым салу объектларының кадастр бәясеннән чыгып, Яңасала авыл җирлеге Советы карар чыгарды:

1. «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының 29.11.2023, № 86 номерлы Яңасала авыл җирлеге Советы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктның 4 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

« 4) 2025-2027 еллар чорына карата 1,2 процент: гомуми мәйданы 1000 квадрат метрдан артык булган административ-эшлекле үзәкләр һәм сәүдә үзәкләре (комплекслар), исемлеккә кертелгән биналар Россия Федерациясе Салым кодексының 378.2 статьясындагы 7 пункты нигезендә билгеләнә;».

2. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2025 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Әлеге карар Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http:pravo.tatarstan.ru) рәсми басылып чыккан көннән алып бер айдан да иртәрәк булмаган вакытта һәм Арча муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Яңасала авыл җирлеге башлыгы А.И.Сафин